Умырзая

МАДОУ 83



Габдулла Тукай
1896 ел,26 апрель
1913 ел,15 апрель

# Проект :

# Габдулла Тукай безнең күңелләрдә!

Төзеделәр: 83нче балалар
бакчасы тәрбиячеләре:
Хурамшина Р.М
Гарипова Л.Н

Умырзая

- **Проектта катнаштылар**: тәрбиячеләр , балалар, әти- әниләр.
- **Проектның төре**: иҗади - сәнгать, матур әдәбият танып белү.
- **Проектның эшләнү вакыты**: 15.03.2023-15.04.2023 ел

Умырзая

**Актуальлеге:**

Күренекле шагыйрь Габдулла Тукайны халкыбыз һәрвакыт күңел түрендә саклый. Аның әсәрләрен балаларда, өлкәннәрдә бик яратып укыйлар, яттан сөйлиләр, чөнки алар матурлыкка, яхшылыкка , гаделлеккә өйрәтә, шәфкатьле, кыю, батыр булырга өнди.

Татар халкының гореф- гадәтләрен, йолаларын, бәйрәмнәрен, халык-аваз иҗатын кече яшьтән үк Тукай әсәрләре аша өйрәнеп үсеп, туган халкыңа, рухи- әхлакый һәм милли мәдәни хәзинәләргә хөрмәтле булу. Г.Тукай әсәрләре аша дурес итеп татарча сөйләргә өйрәнү.

Умырзая

**Проектның максаты:** Балалар бөек шагыйребез Габдулла Тукай тормышы һәм иҗатына кызыксыну уяту.

**Проектның бурычлары:**

1.Балаларны Г.Тукай  әсәрләре белән таныштыру, аның шигырьләрен, әкиятләрен , әсәрләрен истә калдырырга өйрәтү

2.Г.Тукай әсәрләре аша туган якны аның табигатен яратырга, саклый белергә өйрәтү.

3 Тукай иҗаты аша татар халкының үткәнен , хәзергесен чагыштырып татар телен саклап калырга, милләтне , телне югалтмыйча милли мәдәниятебезне саклап калучы шәхесләр тәрбияләү.

4.Балаларда зирәклелек, тапкырлылык, тырышлык, батырлык кыюлык сыйфатларын тәрбияләү.

5 Балаларның хәтерен, уйлау- фикерләү сәләтен үстерү.

Умырзая

**Проект эшчәнлегенең нәтиҗәләре:**

Балаларны Г. Тукай әсәрләре белән таныштыру өчен төркемдә һәм гаиләдә кирәкле шартлар тудыру.

- Габдулла Туай әсәрләрнә балалар күңел ачу чыганагы итеп кенә түгел, танып белү, кызыксыну чыганагы итеп карау.
- Балаларда кызыксынучанлык, иҗади мөмкинлекләр, танып белү активлыгы, коммуникатив мөмкинлекләр үстерү.
- Балаларны үзләренең уй фикерләрен әйтә белергә өйрәтү.
- Проектны тормышка ашырганда ата – аналарның актив катнашуларын күздә тоту.

Умырзая

- Тукай 1886 елның 26 апрелендә кушлавыч авылында (Арча районы Татарстан) Мөхәммәтгариф гаиләсендә дөньяга килә. Аның тууын  ата-анасы бары изге ниятләр белән һәм ак бәхетләр теләп көтеп алса да, язмыш баштан ук аңа карата кырыслык күрсәтә. Алты айлык вакытында атасы, ә дүрт яшендә анасы да үлеп, ул бу доньяда япа-ялгыз кала һәм кулдан-кулга йөртелә башлый. Башта ул Өчиле авылындагы бабасының ишле гаиләсенә эләгә. Анда бу артык тамактан тизрәк котылу ягын карыйлар һәм тиз арада бер ямщикка утыртып Казанга озаталар печән базарында ямщик сабыйны кая куярга белми аптырап йөргәндә Мөхәммәтвәли исемле кеше очрап аны асрау бала итеп ала. Яңа бистәдәге тормышта нәни Габдулла өчен бик кыска гомерле була. Үги әтисе белән әнисе икесе берьюлы авырып китәләр һәм  баланың тагын берүзе калуыннан куркып, аны кабат Өчилегә озаталар.
- Бу авылда яңадан малайны тизрәк каядыр җибәрү ягын карыйлар һәм бераздан аны Сәгъди исемле кеше үзенә уллыкка Кырлайга алып китә. Кырлай авылы хезмәтчел халкы , күңелле бәйрәмнәре һәм матур табигате белән Тукайның хәтерендә кала. Анда да озак яшәргә туры килми яшь Габдуллага. Бу юлы Габдулланы Җаек шәһәрендә яшәгән туганнары үзләренә соратып алалар .

Умырзая

Җаек Тукайга олы белем һәм иҗат дөньясына юл ача. Биредә мәдрәсәдә һәм аның каршындагы рус классында укыганда ул халык иҗаты, татар, рус һәм дөнья әдәбияты белән кызыксына башлый. Бераздан яшь Тукай үзе дә олы шагыйрьлек юлына аяк баса. Матбугаттагы беренче шигъри чыгышыннан ("Голүмең бакчасында", 1905) алып Казанның Клячкин больницасында үлем түшәгендә язылган соңгы шигырьләренә ("Буш вакыт" , "Мәктәп" һ.б.) кадәр ул узенең бөтен иҗади көчләрен туган халкына хезмәт итүгә , аны милләт буларак саклауга һәм үстерүгә багышлады.

- Тукай исән чакта дөнья күргән 34 китабының 16 сы турыдан – туры балаларга, мәктәп укучыларына атап чыгарылган: "Балалар күңеле" (1910), "Күңелле сәхифәләр" (1911), "Энҗе бөртекләре" (1909) һ.б. Тукайның күп шигырьләрен үзе исән чагында ук мәктәпләрдә көйләп күмәк җырлый торган булганнар. Беренче дәрес "Туган тел"е белән башланып, уку елы беткәндә соңгы дәрес тә шул җыр белән тәмамлана.

И туган тел, и матур тел,

Әткәм – әнкәмнең теле.

Дөньяда күп нәрсә белдем,

Син туган тел аркылы.

# Габдулла Тукай иҗаты белән танышу.









Умырзая

МАДОУ 83

# Бакчада үткәрелгән шигырь бәйгесе.





Умырзая

# Брейн- ринг «Син Тукайны беләсеңме? »






Умырзая

МАДОУ 83

# Габдулла тукай туган көненә багышланган бәйрәм иртәсе.






Умырзая

МАДОУ 83

# Габдулла Тукай иҗатына багышлап үткәрелгән бәйрәм иртәләре.





Умырзая

МАДОУ 83

# “Яттан сөйлә Тукай шигырьләрен” дигән шәһәркүләм шигырь бәйгесе.





